**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге**
422742, Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авылы,
Киров урамы, 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кулле-Киминское сельское поселение**
422742, Атнинский муниципальный район
с.Кулле-Кими,
ул. Кирова, 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «02» октября 2024 г. № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2024 елнын 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә керүче Күлле-Киме торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2024 елның 21 ноябре 15.00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;

- сайлау хокукына ия булган Күлле-Киме торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Күлле-Киме торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1)Авыл территориясен төзекләндерү (үләннәрне чабу һәм хезмәтләр өчен түләү, эш һәм хезмәт өчен түләү)

2)Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту,)»

3)Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын һәм яктырткычлар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү)

4) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»

5) Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).

“РИЗА” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күлле-Киме авылы, Киров урамы 1А йорты адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.